**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Базарлы Матак авылы** **КАРАР**

2022 елның 25 марты 100№

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында» 466 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 22 июлендәге « Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 25 июлендәге«Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен федераль башкарма хакимият органнарының матди ресурслары резервларын булдыру, алардан файдалану һәм тулыландыру кагыйдәләрен раслау турында» 1119 номерлы карары белән «Татарстан Республикасы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурсларның резервлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 1119 номерлы карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Әлки муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карар һәм Нигезләмәнең преамбуласында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1996 елның 10 ноябрендәге «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру һәм куллану тәртибе турында»1340 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга.

2 бүлекнең 5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар муниципаль резервка продукция

китерүчеләрне билгеләү 2-13 елның 5 апрелендәге «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.

2 бүлекнең 7 пунктындагы 4 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Хузангай» ҖЧҖ - төзелеш материаллары һәм җиһазлар буенча.»

2 бүлекнең 10 пунктындагы 2 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда аларны бетерү өчен Әлки муниципаль районы резервларының матди ресурслары файдаланыла. Алар җитәрлек булмаганда, Әлки муниципаль районы Башлыгы Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә республика резервларыннан матди ресурслар бүлеп бирү үтенече белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин.»

2 бүлекнең 11 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

4 бүлекнең 16 пунктындагы 4 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Хузангай» ҖЧҖ - төзелеш материаллары һәм җиһазлар буенча.»

Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенчабастырып чыгарырга, Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И.В. Юсупов